МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.05.2021 г.Казань № 289

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 24 маенда 7679 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.07.2015 №533, 06.06.2016 №316, 28.11.2016 №668, 29.03.2017 №194, 08.06.2017 №349, 22.12.2017 №895, 07.05.2018 №351, 18.09.2018 №885, 02.04.2019 №221, 03.09.2019 №666, 14.11.2019 №1012, 06.02.2020 №71, 01.06.2020 №380, 31.12.2020 №1011 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 4 маендагы 289 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсендә (алга таба – Үзәк бүлекчәсе) күрсәтелә.»;

1.4.2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла;»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба – ИАБС) – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы.

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

гаилә әгъзалары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән расланган Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибенең (алга таба – 625 номерлы тәртип) 1.2 пункты нигезендә гаилә составында исәпкә алына торган затлар;

блокка куелган максатчан шәхси счет – банк яки башка кредит оешмасында ачылган, дару чаралары сатып алу өчен түләү алу максатларында Үзәк белән үзара хезмәттәшлек турында килешү төзегән затның шәхси счеты.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон).»;

2 бүлектә:

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсе йөзендә «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

2.3 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге

редакциядә бәян итәргә:

«Балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән рәсмиләштерелә һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә:

язма формада – почта адресы буенча;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына;

смс-хәбәр телефонына.»;

2.5 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Банкта яки башка кредит оешмасында законнарда билгеләнгән тәртиптә социаль түләүләрне күчерү өчен ачылган шәхси счет реквизитларын (балага пособиене банк яки башка кредит оешмасы аша алган очракта) күрсәтеп, балага айлык пособие билгеләү турында гариза:

- әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

- Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла).

2) ның тууын теркәү турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

3) гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе;

4) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының гариза тапшырылган айга кадәр алты календарь аеннан алда килгән соңгы 12 календарь ае өчен керемнәрен раслый торган документлар:

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү оешмаларында укучыларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучы аспирантларга һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның дини белем бирү оешмаларында укучы дикторантларга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм турында белешмә;

гаилә әгъзалары ала торган алиментлар турында белешмә;

5) чит ил дәүләте территориясендә бирелгән Россия Федерациясеннән читтә белем алу турында документ күчермәләре һәм гомуми белем бирү оешмасында белем ала торган 16 яшьтән олырак бала өчен әлеге документның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе;

6) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында хокуклары теркәлмәгән, гаилә әгъзалары милкендә булган күчемсез милек объектларына хокук билгели торган документларның күчермәләре;

7) әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнарның гаилә составына Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4

пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның катлаулы формасыннан интегүче затлар кергән очракта, мондый авыру белән законнар нигезендә бергә яшәве мөмкин булмаган очракта, гаилә әгъзасында Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән, законнар нигезендә бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган хроник авыруның катлаулы формасы булуы турында белешмә;

8) мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән (ирекле формада) документ(лар), түбәндәгеләрне раслый торган:

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуын;

шәхси мәгълүматларны органга яисә оешмага тапшырганда мөрәҗәгать итүченең алар исеменнән эш кылуга вәкаләтле булуын.

Ялгыз ана баласына айлык пособие алу өчен мөрәҗәгать иткән затлар өстәмә рәвештә ГХАТ органнарыннан баланың атасы турында белешмәләрне туу турында таныклыкка кертү нигезе турында белешмә тапшыра.

Чакыру буенча хәрби хезмәт уза торган хәрби хезмәткәрнең баласына айлык пособие алу өчен мөрәҗәгать итүче зат өстәмә рәвештә баланың атасын хәрби хезмәткә чакыру турында хәрби комиссариаттан белешмә яки баланың атасының белем алуы турында һөнәри белем бирүче хәрби мәгариф учреждениесеннән белешмә тапшыра.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документларның электрон үрнәкләре яки электрон формадагы документлар мондый документларны булдыру һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан да, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәсе белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гаризаны шулай ук Үзәк бүлекчәсендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аны мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, имзалый.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:

1) Үзәк бүлекчәсендә кәгазьдә;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

3) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре аша.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасында документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын písларга кирәк.

Зеленодольск шәһәрендә яшәүчеләр өстәмә рәвештә гаризаны Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрә ала, аларның адреслары Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган.

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә карата таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә карата таләпләр (алга таба – Таләпләр)» сүзләрен өстәргә;

2.6 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәге белешмәләр алына:

күчемсез мөлкәт булуы турында;

билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техникасы булуы турында;

балага айлык пособие билгеләү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

уналты яшеннән олырак баланың (балаларның) гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында;

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә алучы ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында;

опека (химаяче) билгеләү һәм опекунның (химаяченең) баланы асрауга акча алуы турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында;

әҗәте булган затның иректән мәхрүм итү, арест астында тору, мәҗбүри дәвалануда булу рәвешендә җәза үтүгә бәйле рәвештә алимент түләттерелә алмый торган затның кереме булмавы турында;

алимент түләүдән читләшү сәбәпле, ата-аналарны эзләтү турында;

җинаять кылган өчен ата-аналарны җинаять җаваплылыгына тарту турында.

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша мөрәҗәгать иткән очракта, өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөрәҗәгать итүченең паспортының чынлыгын раслау турында мәгълүмат алына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт

органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына «Таләпләр» сүзен өстәргә;

2.7 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булуы;

2) Үзәк бүлекчәсенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшырылуы;

3) күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә төп документларның күрсәтелмәве;

4) мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе;

5) мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итәргә вәкаләтле затның мөрәҗәгать итүченең яшәгән урынына карамаган Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүе.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Нигезләмәнең 3.17 пункты» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына «Таләпләр» сүзен өстәргә;

2.8 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе.

Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына «Таләпләр» сүзен өстәргә;

2.16 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсе телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына языл у мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Алдан язылганда мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-расламаны чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә,

күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланганнан соң 15 минут узу белән, ул килмәгән очракта алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында мөрәҗәгать итүчегә зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан броньлап кую өчен кирәкле вакыт аралыгы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләр тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән бүтән гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза биргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада бирелә»;

2.16 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына «Таләпләр» сүзен өстәргә;

3 бүлектә:

3.3.1 пунктчаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Мөрәҗәгать итүче балага пособие билгеләү турындагы гаризаны Үзәк бүлекчәсенә әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны теркәп тапшыра.Р116

Гариза һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган документларның күчермәләре почта юлламасы итеп җибәрелергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизацияләү уза;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә

имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрә ала.

Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, кергәндә беркетелгән номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында тамгалап, мөрәҗәгать итүчегә язу тапшыра, гариза почта буенча һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелгән очракта, гаризаны теркәү датасы һәм алынганда беркетелгән номеры турында белдерү җибәрә яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына гаризаны теркәү турында белдерү җибәрә (гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Инфоматлары аша җибәрелгән очракта).

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән алганда, Үзәк бүлекчәсе белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша биргән очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар алынган көнне;

гариза һәм документлар Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша килгәндә яки гариза һәм документлар, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе эш

көнендә. Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлекчәсенең ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы, документларны кабул итү турында язу яисә мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язмача) белдерү.»;

3.4.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече электрон формада вәкаләтле органнардан түбәндәге мәгълүматларны ала:

үзара хезмәттәшлек турында Үзәк белән килешү төзегән банктан яки башка кредит оешмасыннан блокка куелган махсус шәхси счет реквизитлары турында (мөрәҗәгать итүче буларак өч яшенә кадәрге баланың ата-анасы (законлы вәкиле) мөрәҗәгать иткән очракта);

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында.»;

3.4.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Балага пособие билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә булмаган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

күчемсез мөлкәт булуы турында;

билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техникасы булуы турында;

балага айлык пособие билгеләү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

уналты яшеннән олырак баланың (балаларның) гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында;

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә алучы ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында;

опека (химаяче) билгеләү һәм опекунның (химаяченең) баланы асрауга акча алуы турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында;

әҗәте булган затның иректән мәхрүм итү, арест астында тору, мәҗбүри дәвалануда булу рәвешендә җәза үтүгә бәйле рәвештә алимент түләттерелә алмый торган затның кереме булмавы турында;

алимент түләүдән читләшү сәбәпле, ата-аналарны эзләтү турында;

җинаять кылган өчен ата-аналарны җинаять җаваплылыгына тарту турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.»;

3.6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән (язмача формада почта адресы буенча, электрон формада электрон почта адресы буенча, телефонга смс-хәбәр юллап, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша) балага пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) хәбәр итә. Бу вакытта, өч яшькә кадәрге баланың ата-анасы (законлы вәкиле) булган мөрәҗәгать итүче тарафыннан ачылган, блокка куелган максатчан шәхси счет реквизитлары турындагы белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә булмаган очракта, балага пособие билгеләү турындагыбелдерү язуында Үзәк бүлекчәсе белгече шулай ук мөрәҗәгать итүчегә блокка куелган максатчан шәхси счет ачу кирәклеге турында да күрсәтә.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 3 нче кушымта

форма

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре)
республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе

________________________________________

________________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

Балага айлык пособие билгеләү турында карар

№______ _________ 20__ ел.

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)_____________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы: _____________________________________________

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 16 яшькә кадәрге (гомуми белем бирү оешмасында укучы бала өчен – ул укып бетергәнче, ләкин 18 яше тулганчы гына) айлык пособие билгеләргә (кемгә) _____________________________________________
(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме)
___________________ сум күләмендә

Түләү вакыты: ____ башлап _____ кадәр

<*> Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алу өчен түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары нигезендә дару чаралары сатып алу өчен 5 000 сум күләмендә түләү билгеләргә.

Түләү ысулы: ____________________________________

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе ____________________________

_____________________________________________ ____________________ ________________
муниципаль районда (шәһәр округында) (фамилия, исем, ата исеме) (имза)

мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе белгече

_____________________________________________ ____________________ ________________
муниципаль районда (шәһәр округында) (фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):
язмача
смс-хәбәр ___________________________________
(телефон номеры)
электрон почта буенча ____________________________________________
(электрон почта адресы)

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм
муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында
шәхси кабинет аша

<*> «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ бүлекчәсендә өч яшькә кадәрге баланың ата-анасы (законлы вәкиле) булган мөрәҗәгать итүче тарафыннан ачылган блокланган максатчан шәхси счет реквизитлары турында белешмәләр булган очракта, балага айлык пособие билгеләү турындагы карарда күрсәтелә

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре)
республика үзәге» ДКУ №_____
бүлекчәсе
___________________________________

___________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Балага айлык пособие билгеләүдән баш тарту турында карар

№_______ __________ 20__ ел.

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) ______________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы: ______________________________________

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 16 яшькә кадәрге (гомуми белем бирү оешмасында укучы бала өчен – ул укып бетергәнче, ләкин 18 яше тулганчы гына) айлык пособие билгеләүдән баш тартырга (кемгә) ________________________________
(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Баш тарту сәбәбе: ______________________________________________

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе житәкчесе ____________________________

______________________________ ______________________ ______________
муниципаль районда (шәһәр округында) (фамилия, исем, ата исеме) (имза)

мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәге» ДКУ _ номерлы бүлекчәсе белгече

______________________________ ______________________ ______________
муниципаль районда (шәһәр округында) (фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):
язмача
смс-хәбәр белән ________________________
(телефон номеры)
электрон почта аша _______________________________________
(электрон почта адресы)
Татарстан Республикасы Дәүләт һәм
муниципаль хезмәтләр күрсәтү
порталында шәхси кабинет аша».